# TATAR SCHOLARS IN EXILE: KURAT AKDES

**Leisan Shahin,**
Marmara University, Scientific
Research Institute of Turkish Studies,
Turkey, 34722, Istanbul, Kadıköy,
leysan_shahin@mail.ru



**KURAT AKDES NIGMAT** (Nigmatov Akdes Tahirovich, 1903-1971) was a historian and a Doctor of Philosophy (1933). He was born in the Menzelinsky district of Ufa, Russia. In1924, he emigrated to Turkey. From 1929 to 1933, he studied in Germany. From 1933 to 1937, he taught at Istanbul University. Beginning in 1939, he worked at Gazi Pedagogical Institute (Ankara) where he received his professor's degree in 1944. He was the Dean of Faculty of the Department of Languages, History and Geography from 1953 to 1955. From 1946, this scientist went on numerous scientific missions to Iran, Afghanistan, England, the USA, Australia, Brazil, Mexico and other countries.

His well-known works are devoted to the history of the Turks of Eastern Europe. He also published decrees and letters of the khans of the Golden Horde.

**КУРАТ ӘКЪДӘС НИГЪМӘТ** (Нигъмәтов Әкъдәс Таһир улы, 1903-1971) − тарихчы, философия докторы (1933). Россиянең Уфа губернасы Минзәлә өязендә туа. 1924 елдан − Төркиядә эмиграциядә. 1929-1933 елларда Германиядә белемен күтәрә. 1933−1937 елларда Истанбул университетында укыта. 1939 елдан Гази педагогика институтында (Анкара) эшли, профессор дәрәҗәсенә лаек була (1944), тел, тарих һәм география факультеты деканы вазифасын башкара (1953−1955), 1946 елдан Иран, Әфганстан, Англия, АКШ, Австралия, Бразилия, Мексика һ.б. илләрдә фәнни командировкаларда була.

Хезмәтләре Көнчыгыш Европада яшәгән төрки халыклар тарихына карый. Алтын Урда ханнары ярлыкларын һәм хатларын бастырып чыгара.

**КУРАТ АКДЕС НИГМАТ** (Нигматов Акдес Тагирович, 1903-1971) − историк, доктор философии (1933). Родился в Мензелинском уезде Уфимской губернии России. В 1924 году эмигрировал в Турцию. В 1923-33 г.г. – в научной командировке в Германии. В 1933-37 г.г. преподает в Стамбульском университете, с 1939 года – в педагогическом институте Гази (Анкара); проф. (1944), декан факультета языка, истории и географии (1953-55), с 1946 в научных командировках в Иране, Афганистане, Англии, США, Австралии, Бразилии, Мексике и др.

Труды по истории тюркских народов, проживающих в Восточной Европе. Опубликовал ярлыки и письма ханов Золотой Орды.

The Tatar people, since time long past, were scattered by fate, a fate which sometimes drove them far away. Many people left their homeland for other countries, searching for happiness, each with their own goals and reasons for staying abroad. Each story of immigration is instructive. We can see in the Tatar people such characteristics as studiousness, dexterity, diligence, and persistence. Seeking greater happiness in foreign countries was always accompanied by many severe

events, by everyday necessities. The history of Tatar emigres, however, is also a story about overcoming difficulty, standing on one's feet in a new place, earning the respect of the local population and gaining a worthy position in their society.

The protagonist of our article is a Turkish scientist, a historian and professor. Kurat Akdes Nigmat, who left his homeland as a young man, dwelled in Turkey and earned a reputation through his broad knowledge and abilities.His biography is the story of a hardworking and dedicated man who was engaged in science and persistently sought knowledge throughout his life. He tried to do his best at everything, when doing his job and research, creating and trying to do everything as perfectly as he could.

After finishing primary school, Nigmat's father sent him and his brother, Asgat, to a Russian secondary school in Bugulminsk province. The boys lived in the house of the historian Khadi Atlasi, as relatives of his wife, Shakira. Nigmat was very hardworking and a year later, owing to his diligence, he passed his exams and was enrolled in a Russian non-classical secondary school, where such subjects as mathematics, physics, history, geography, German and French were taught. The intelligent Nigmat studied on par with Russian-speaking students and he was one of the top two students in his class.

On August 7, 1922, on receiving a blessing from his parents, Nigmat left Barkat for Germany, where he wished to continue his studies. It was the last time he saw his parents and relatives and a farewell to his homeland.

In August, 1922, the most difficult period in Nigmat's life began and it lasted for three years. This poorly dressed and penniless fellow, lacking identity documents, moved to Chally, then to Kazan, Moscow and Petrograd.

At first he tried to cross the border with Latvia illegally, as he had no passport, for which he spent a month in prison. Later, he tried to cross the border with Lithuania, but the something happened. The third time he reached Poland and again he was sent to prison. He spent a few months on the streets of Poland after he had been set free. In the end, he was employed by a rich Polish farmer and worked for him for a year and a half. He decided not to waste time and learn the Polish language.

Not having any opportunity to go to Germany, he appealed to the Turkish consul in Warsaw and asked them to send him to Turkey. The Turks did not refuse and helped him obtain a passport. Finally, Nigmat was sent to Istanbul in November, 1924. There, he met with Tatar celebrities, in particular, with Yusuf Akchura and Sadri Maksudi. Despite his acquaintance with them, he hesitated to ask for their help, because at that time he was dressed in an expensive coat, which had beenbought by Tatars living in Warsaw.

Nigmat devoted all his time to reading books and studying the Turkish language. At Istanbul University he asked Fuat Kupruli, director and professor of the newly founded Turkological Institute of Istanbul University, to give him an opportunity to work there. "I know Russian, Polish and some German and I can put your library in order", he said. Nigmat's knowledge of languages interested Kupruli and he decided to hire him. Nigmat started work as an assistant in the Turkological Institute of Istanbul University on August 25, 1925 and decided at that moment to enter the History department. In 1929-1933, his dream came true and he went to study in Germany. In 1933, he completed his thesis on the history of Byzantium and got his PhD degree in Historical Sciences.

He returned to Turkey again in 1933. He was an assistant professor at the University of Istanbul. At this time, Nigmat devoted his life to scientific research. He worked hard, liberalizing and studying new horizons of science. He wrote new books and published articles. There was a new law on modern surnames in Turkey and Nigmat decided to have the surname of 'Kurat,'its origin is in the verb *"kurmak"*–'to build, to make'. The new surname emphasized his hard-working nature.

At this time, there were a lot of people who envied his studiousness, dexterity, and diligence and who would have liked to put a fly in his ointment. They did not like Akdes'way of calling a spade a spade. As a result, Kurat lost the opportunity to work hard and decided to leave the University. Before that, he had visited Sweden and there was a possibility to move to this country. Consequently, he accepted the position of a Sweden University professor. He kept working hard there. Besides reading lectures at Uppsala University, he studied the material for his new books in the University Library. Kurat visited the archives of Berlin, Dresden, Munich, Vienna and Paris.

His work required him to return Turkey after some time, however again, he met with those who were envious of his success. He, who had received a Doctor's degree in Germany, a scholar who read lectures in Sweden, worked in the European archives, was sent to the small town of Denizli in Turkey to teach history in a high school. It was done through the efforts of his enemies. Neverthe-

less, Akdes never gave up. He devoted his time to arranging the materials collected in the archives for his new books. In 1939, he moved to Ankara and worked as a school teacher of history.

He was later sent to teach the Russian language at the Language, History and Geography faculty of Ankara University and he was appointed a scientist assistant, as a demonstration of his inferior position.

Kurat wanted to take assistant professor exams but his application was refused for many reasons, many times. In 1940, he became an assistant professor and started work as an assistant professor of history in the faculty of Language, History and Geography. He wanted to be a professor but met a lot of difficulties on his way. Only in 1943, did Akdes Kurat became a professor.

After becoming a professor, all obstacles in his way disappeared. He worked a lot, wrote many books and articles, worked in the archives of other countries (European countries and the USA), maintained contacts with many outstanding scientists, and took part in many conferences. He learned many languages to have an opportunity to read archive documents in the original. He knew Russian, Polish, German, Turkish, English, Swedish, and French very well. He studied many topics from history. The scientist wrote nineteen books and more than seventy articles.

In 1953-1955, he was the dean of the Language, History and Geography faculty. During these years he arranged more than fifty colloquiums on history. As his colloquiums were interesting both for learning and research, the number of scientists and common folk, even politicians, who wanted to attend these colloquiums kept growing.

Akdes Nigmat Kurat became very famous in Turkey. People knew he was a very talented scholar. In 1980, he was invited to the Orientalist's congress. The government of Turkey entrusted a great deal to him. They asked him to arrange conferences which would make Turkey more popular in different countries. A special program was devised by the Ministry of External Relations of Turkey. Akdes Kurat arranged conferences and seminars all over the world, Iran, Afghanistan, Australia, North and South America and other countries.

Unfortunately, he died in 1968 in an accident. On August 28, 1971, he left Ankara for Istanbul and his bus ran into a car. Akdes was wounded and in ten days he died on September, 8, 1971. After a farewell at the Literature Faculty of Istanbul University and his funeral in Kadikoy Osmanda mosque, he was buried in Arkanai cemetery.

**References**


1. *Akder Necati.* Profesör Akdes Nimet Kurat'ın Ardından: Hatıralar ve Düşünceler // Türk Kültürü, 1971, no. 108 (Ekim), s. 913-927.(in Turkish).
2. *Turan Osman*. Bir Alim ve İdealistin Kaybı. // Belgelerle Türk Tarihi Dergisi, 1971, no. 48 (Eylül), s. 30-33. (in Turkish).
3. *Baştav Şerif.* Kazan Türklerinden Prof. Dr. Akdes Nimet Kurat // Türkiye Cumhuriyeti Devletinin Kuruluş ve Gelişmesine Hizmeti Geçen Türk Dünyası Aydınları Sempozyumu Bildirileri: 23−26 Mayıs 1996. Haz. Abdulkadir Yuvalı vb. Kayseri: Erciyes Üniversitesi Yay. 1996, s. 119-126. (in Turkish).
4. *Shäräfetdinov F.* Ћižrättäge böek millättäshebez // Gasyrlar avazy − Ekho vekov. 2002. № 3-4, 167-171 b. (in Tatar).


# МӨҺАҖИРЛЕКТӘ ТАТАР ГАЛИМНӘРЕ: ӘКЪДӘС КУРАТ


**Ләйсән Шаһин**,
Мәрмәрә университеты,
Төркия тикшеренүләре институты,
Төркия, 34722, Кадыкей, Истанбул,
leysan_shahin@mail.ru


Элек-электән язмыш җилләре татар халкын тузгытып килгән, вакыт-вакыт татар кешеләрен шактый еракларга ук илтеп ташлаган. Тарихи ватаннан чыгып китеп, чит-ят җирләрдә бәхет эзләргә аларны төрле максатлар һәм зарурлыклар этәргән, анда төпләнеп яшәп калуларына да шулай ук төрле хәлләр сәбәпче булган.

Шунысы мөһим: һиҗрәт хикәяләренең һәрберсе үзенчә гыйбрәтле. Аларда татар халкының тырышлык, уңганлык, эш сөючәнлек, яхшы мәгънәдә үҗәтлек сыйфатлары ачык чагыла. Чит җирләрдә бәхет эзләүнең һәр очрагы авыр хәлләргә тару, җәфа чигүләргә бәйле булган. Ләкин, шул ук вакытта, һиҗрәттәге татарларның тарихы –

очраган кыенлыкларны берәм-берәм җиңеп бару, яңа урында тернәкләнеп, аякка басып китү, хәтта шул төбәктәге җирле халыкның тәкъдирен һәм хөрмәтен казанып, чит җәмгыятьтә лаеклы урын яулап алуның тарихы ул.

Мәкаләбез каһарманы – туган туфрагыннан яшьли чыгып китеп, ялгыз башы төрле маҗаралар кичергәннән соң, Төркиягә барып төпләнгән, төрек җирендә бары тик үз акыл көченә һәм сәләтенә генә таянып, җәмгыятьтә югары дәрәҗә яулауга ирешкән, Төркиянең санаулы зур галимнәреннән берсе булып киткән тарихчы, профессор Әкъдәс Нигъмәт Курат. Аның биографиясе – гомере буе белемгә омтылып яшәгән, белем өлкәсендә гел алга һәм югарыга таба баруны үзенә максат итеп куйган, гомумән, һәр кылган гамәлендә камиллеккә ирешергә тырышкан, туктаусыз иҗтиһат иткән тынгысыз, искиткеч эшчән затның тормыш юлы ул.

Башлангыч мәктәпне тәмамлагач, Әкъдәс белән Әсгатьне әтиләре Бөгелмәдәге рус урта мәктәбенә илтә. Малайлар тарихчы Һади Атласиның өендә яшиләр. Әкъдәс тырышлыкта энесен узып китә, бер елдан соң үз теләге, үз тырышлыгы белән имтихан биреп, рус реаль училищесына укырга керә. Монда математика, физика, тарих, география, алман һәм француз телләре укытыла. Зирәк Әкъдәс дәресләрдә рус балалары белән тигез бара.

1922 елның 7 августында ата-ана фатихасын алып, Әкъдәс, Алманиягә укырга бару нияте белән, Бәркәтәдән чыгып китә. Туган авылын, әти-әнисен, туганнарын соңгы тапкыр күрүе була яшь егетнең.

1922 елның августыннан Әкъдәс өчен өч елга сузылган бик авыр чор башлана. Бер тиенсез, документсыз, юка өс-баш белән генә чыгып киткән егет башта Чаллыга, аннан Казанга, Мәскәүгә, аннары Петроградка барып җитә. Россия чиген качып узып, башта Латвиягә кереп карый. Паспорты булмаганга, аны кулга алалар, бер ай төрмәдә ятканнан соң, кире кайтарып җибәрәләр. Аннары ул Литва чиген үтә, анда да шул ук хәл кабатлана. Өченче тапкырында Польшага барып юлыга, тагын тоткынлыкка эләгә. Төрмәдән чыккач, Польшаның бер шәһәрендә берничә ай урамда кунып йөри. Ахырдан бер бай полякның фермасына эшкә урнашып, ел ярым шунда хезмәт куя. Вакытын бушка үткәрми, шул арада поляк телен өйрәнә.

Алманиягә барырга берничек тә җай табылмагач, Варшавадагы төрек консуллыгына мөрәҗәгать итә һәм Төркиягә җибәрүләрен сорый. Төрекләр татар егетен кире какмыйлар, паспорт ясап бирәләр. Ниһаять, Әкъдәс 1924 елның ноябрендә Кара диңгез юлы белән Истанбулга килә. Йосыф Акчура, Садри Максуди кебек күренекле шәхесләр белән күрешеп, танышып китә.

Әкъдәс төрек телен өйрәнә, Истанбул университеты китапханәсенә барып, китаплар укый. Ахырдан, әрсезләнеп, Истанбул университетында әле яңа гына оештырылган Тюркология институтының мөдире профессор Фуат Көпрүледән эш сорый. «Мин рус, поляк телләрен, әзрәк алман телен беләм, сезнең китапханәне тәртипкә салырмын», − ди. Тел беләм дигәч, Көпрүле кызыксынып, егетне эшкә алырга риза була. Шул көннән (1925 елның 25 августы) башлап Әкъдәс Истанбул университетының Тюркология институтында ассистент булып эшләп китә, шул ук вакытта Тарих бүлегенә студент булып та языла. 1929−1933 елларда, күптәнге хыялын тормышка ашырып, Алманиядә белемен күтәрә. 1933 елда Византия тарихына кагылышлы темага багышланган диссертациясен тәмамлап, тарих фәне докторы дәрәҗәсен ала.

1933 елда ул кабат Төркиягә кайта. Истанбул университетында урта гасырлар чоры буенча лекция укый башлый. Шул вакытта Әкъдәс өчен фән тормышы башланып китә. Ул бик бирелеп, тырышып эшли, бу юлда гел алга бара, югарыга күтәрелә. Бер-бер артлы саллы-саллы китаплар чыгара башлый, мәкаләләр яза. 1934 елда Төркиядә заманча фамилияләр алу турында канун чыккач, Әкъдәс үзенә «курмак» (кору, төзү, ясау) фигыленнән ясалган «Курат» фамилиясен сайлый. Яңа фамилиясе дә аның тырышлыгын, активлыгын ассызыклап тора.

Ләкин университетта Куратның уңышларыннан көнләшүчеләр, тырышлыгын, зирәклеген ошатмаучылар аңа аяк чала башлыйлар. Аларга Әкъдәснең туры сүзле холкы, әйтәсе сүзен, тәнкыйтен йөзгә бәреп әйтә торган гадәте ошамый. Эшләү мөмкинлеге калмагач, ул Истанбул университетын ташлап, таныш профессорларының чакыруын кабул итеп, Швециягә эшләргә китә. Швециядә Уппсала университетында лекцияләр укып кына калмый, дәүләт архивында язылачы китаплары өчен бай материал туплый. Эшләгән урынының юлламасы белән Берлин, Дрезден,

Мюнхен, Вена, Париж, Лондон архивларына да барып эшләп кайта.

Мәҗбүри хезмәт вазифасын үтәр өчен, Төркиягә кире кайткач, көнче мәсләктәшләре аңа кабат аяк чала башлыйлар. Алманиядә фәннәр докторы дәрәҗәсен алган, Швециядә лекцияләр укыган, Аурора архивларында эшләгән галимне, шулар «тырышлыгы» белән, Төркиянең Денизли дигән кечкенә шәһәрчегенә урта мәктәпкә тарих укытучысы итеп җибәрәләр. Әлбәттә, Әкъдәс монда да тик ятмый, Аурора архивларында җыйган материалларын тәртипкә сала, боларга нигезләнеп, яңа хезмәтләрен яза. 1939 елны Әкъдәсне Анкарага күчерәләр. Ул монда бер училищеда тарих укытучысы булып эшли. Шуның өстенә, Анкара университетының Тел, тарих һәм география факультетында рус теле укытырга кушып, аны «гыйльми ярдәмче» дигән иң түбән вазифага билгелиләр.

Әкъдәснең доцентлык имтиханына керү өчен мөрәҗәгате төрле сәбәпләр белән кире борылып, гел кичектерелеп килә. 1940 елда, ниһаять, ул имтиханны тапшыра һәм Тел, тарих һәм география факультетында тарих буенча доцент дәрәҗәсендә эшли башлый. Аның профессорлыкка мөрәҗәгате дә янә төрле киртәләргә юлыга. 1944 елда аңа рус теле һәм әдәбияты профессоры исеме бирелә. Бары тик 1946 елда гына Әкъдәс Курат үз белгечлеге буенча (урта гасырлар тарихы) профессорлык дәрәҗәсен алуга ирешә.

Профессор булганнан соң, Әкъдәс аганың юлындагы бөтен киртәләр юкка чыга. Ул беркемгә дә карамыйча бирелеп эшли, бер-бер артлы китаплар, мәкаләләр яза, күп тапкырлар чит илләрдә (төрле Аурора илләрендә һәм Америка Кушма Штатларында) архивларда эшләп кайта, күренекле галимнәр белән элемтәдә тора, күпсанлы конференцияләрдә катнаша. Архив документларын язылган телләрендә укыр өчен, яңа телләр өйрәнә. Рус, поляк, алман, төрек телләреннән тыш инглиз, швед, француз телләрен дә камил белә. Тарих фәне өлкәсендә күп төрле темаларны тикшерә, җәмгысы 19 китап, 70 тән артык мәкалә яза.

1953-1955 елларда ул Анкара университеты Тел, тарих һәм география факультетында декан булып тора. Деканлык вазифасын башкарганда, уку йортында тарих буенча 50дән артык коллоквиум оештыра. Бу коллоквиумнар бөтен Анкарада дан тота, аларны тыңларга күп кеше килә, галимнәр һәм гади халыктан тыш чыгышларын танылган сәясәтчеләр дә тыңлый.

Шулай итеп, Әкъдәс Нигъмәт Курат Төркиядә зур галим булып танылa. 1970 елда Австралиядә узачак Ориенталистлар конгрессына чакыру алгач, Төркия хөкүмәте Әкъдәс агага зур вазифа йөкли. Австралиягә бару уңаеннан Әкъдәс агадан төрле илләрдә Төркияне таныта торган конференцияләр уздыруын үтенәләр. Ул, бу вазифаны үтәр өчен, Төркия тышкы эшләр министрлыгының махсус төзелгән программасы буенча, Иран һәм Әфганстаннан башлап, Австралияне, Көньяк һәм Төньяк Америка илләрен урап, бик күп илләрдә булып, һәр тукталышта конференция яки семинарлар ясап, дөнья тирәли әйләнеп кайта.

Бәхетсезлеккә каршы, бу фәнни сәяхәттән соң берничә ай гына үткәч, 68 яшен тутырган Әкъдәс аганың гомере кинәттән өзелә. 1971 елның 28 августында Анкарадан Истанбулга барганда, галим утырган автобус машина белән бәрелешеп, әйләнеп каплана. Шул авариядә Әкъдәс ага бик каты яралана һәм 8 сентябрьдә вафат була. 10 сентябрьдә Истанбул университеты Әдәбият факультеты алдында оештырылган саубуллашу йоласыннан соң Кадыкөй Османага мәчетендә җеназа укылып, Әрәнкөй зиратына җирләнә.

**Әдәбият**


1. *Akder Necati.* Profesör Akdes Nimet Kurat'ın Ardından: Hatıralar ve Düşünceler // Türk Kültürü, 1971, no. 108 (Ekim), s. 913-927 (төрек телендә).
2. *Turan Osman.* Bir Alim ve İdealistin Kaybı. // Belgelerle Türk Tarihi Dergisi, 1971, no. 48 (Eylül), s. 30-33 (төрек телендә).
3. *Baştav Şerif.* Kazan Türklerinden Prof. Dr. Akdes Nimet Kurat // Türkiye Cumhuriyeti Devletinin Kuruluş ve Gelişmesine Hizmeti Geçen Türk Dünyası Aydınları Sempozyumu Bildirileri: 23−26 Mayıs 1996. Haz. Abdulkadir Yuvalı vb. Kayseri: Erciyes Üniversitesi Yay. 1996, s. 119-126 (төрек телендә).
4. *Шәрәфетдинов Ф.* Һиҗрәттәге бөек милләттәшебез // Гасырлар авазы − Эхо веков. 2002. № 3-4, 167-171 б.